# Чишмә башы



**Хәсәншәех балалар бакчасы**

**5 нче сан, март**

## Яз килә!





Яз кояшы елмаеп карау белән, бөтен табигать кышкы йокысыннан уяна башлый. Кояш балкый, ул өй түбәләрендәге карларны эретә. Карлар эри башлагач, җылы яклардан кошлар да кайта башлар. Язгы җылы җил агачтагы яшь бөреләрне уятыр. Тиздән алар хуш исле яшел яфраклар ярырлар. Кояш эссе нурларын көннән-көн күбрәк сибәр. Җирдән җырлый-җырлый гөрләвекләр челтерәп агар. Бозлар кузгалыр. Кырларда беренче умырзая баш калкытыр. Кешеләр язгы эшләргә керешерләр. Язның да эше күп: иңе-буе күренмәгән кырларны кардан әрчисе, ямь-яшел уҗым басуларын ачасы бар. Кырларда тиздән тракторлар гөрләр – язгы кыр эшләре башланыр. Язның әле дымлы җирне үләннәр һәм аллы-гөлле чәчәкләр белән бизисе бар. Ә бүген әле март башы гына. Төннәрен салкын булса да, көндезен инде кояш балкый. Туган җиребезгә яз килә, яз исе аңкый. Яз – матур, шатлыкларга бай, күңелле вакыт.

Түрдән уз, яз!






Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Күктән нурлар сибелә.
Туган илем, туган җирем
Язны күреп сөенә.

Март ае-яз башы,бик матур ай. 21 нче мартта бакчабызда Нәүрүз бәйрәме үткәрдек.Бу ай озак заманнар буе яңа елның беренче ае булып йөргән. Нәүрүз –язны каршылап ,язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Нәүрүз-ул игелек,дуслык бәйрәме. Ул тынычлыкка, матурлыкка өндәүче бәйрәм. Бәйрәмнең хуҗасы-сөйкемле Нәүрүзбикә.Әлеге бәйрәм язгы яңарыш, уңыш, дуслык, мәхәббәт символы булып санала. Борынгыдан килгән гореф-гадәт буенча, Нәүрүз килер алдыннан кешеләр өйләрен чистартып, хуҗалыкларын тәртипкә китереп, алган бурычларын кире кайтарырга тиеш. Имеш, Нәүрүз чиста йортка, яхшы өй хуҗасына килеп керсә, аны авырулар, уңышсызлыклар читләтеп узган. Ә бәйрәм көн бары тик кич утырулар, кунакка йөрүләр, очрашулар, күңел ачуларга багышлана. Борынгылар фикеренчә, Нәүрүзне шат күңел һәм сый-хөрмәт белән каршы алсаң, ул өйгә муллык һәм ел буена уңыш китерер.





# Уңышларыбыз




Бакчабызда балалар Татнетны үстерү фонды белән берлектә үткәрелгән "Күңелем сәйләннәре" төбәкара онлайн шигырь укучылар бәйгесендә катнаштылар. Җиңүчеләрне чын күңелебездән тәбрик итәбез





Тәрбиячебез Хисамиева Ләйсән Илсур кызы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең татар телендә белем бирүче тәрбиячеләре арасында үткәрелгән " Иң милли тәрбияче - 2025 " республикакүләм бәйгесендә " Иң яхшы милли бәйрәм"номинациясендә 2 нче урынга лаек булды. Котлыйбыз! Киләчәктә дә матур уңышларыгыз күп булсын!.







Идел буе республикаларында яшәүче халыкларның милли мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән кызыксыну уяту, педагогик җәмәгатьчелек, ата-аналар һәм балалар арасында иҗади элемтәләрне киңәйтү һәм ныгыту максатыннан үткәрелгән «Мирас чыганаклары» видеороликлар конкурсында катнашып, Фәхретдинова Язгөл  лауреат дәрәҗәсендәге диплом белән бүләкләнде.



# *Туган телем сагында*



27 нче март – Халыкара театр көне. Театр – сәнгатьнең иң гүзәл төре. Ул кешеләрне көлдерә дә, елата да, уйландыра да... Театр – тормышның көзгесе. Ул халкыбызның рухын ныгыта, теленә, гореф - гадәтенә мәхәббәт уята. Төрле халыклар арасында дуслыкны арттыра, берләштерә.



Театр – грек теленнән тәрҗемә иткәндә «тамаша өчен урын» дигәнне аңлата. Театр тамашачы булган җирдә башлана, диләр. Ягъни бер генә театр да тамашачысыз булмый.

Беренче театр Борынгы Грециядә барлыкка килгән. Ул ачык һавада ярымтүгәрәк формада төзелә. Хатын-кызларга тамаша карарга рөхсәт ителмәгән, шуңа күрә театрга ир-атлар гына йөргән.



Россиядә театр 17нче гасырның икенче яртысында барлыкка килгән. Бүгенге көндә аның бик күп төрләре бар. Мәсәлән, драма, опера, балет, курчак, пантомима театрлары.

Дөньядагы иң зур театр Кытайда урнашкан. «Судагы энҗе бөртеге» дип аталучы әлеге театрның биеклеге – 50, киңлеге – 215, озынлыгы – 145 метр. Ә иң кечкенә театр Австриянең Филла шәһәрендә урнашкан. Ул «Кирмән ишегалды» дип атала һәм нибары 8 генә тамашачыны сыйдыра.



Театрның төп символы – ике маска. Аларның берсе гел елмая, икенчесе – һәрвакыт күңелсез. Бу ике маска трагедия һәм комедияне, яхшылык белән яманлыкны чагылдыра.

Әлеге көн уңаеннан зурлар төркеменә йөрүчеләр Муса Җәлил әсәрләрен сәхнәләштерделәр